**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**БОЕРЫГЫ**

10.10.2024 № 343

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау мәсьәләләре буенча ведомствоара эш төркеме турында» боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау мәсьәләләре буенча ведомствоара эш төркеме турында» 2016 елның 7 мартындагы 170 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 11 маендагы 184 номерлы, 2019 елның 27 августындагы 300 номерлы боерыклары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 6 апрелендәге 136 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау мәсьәләләре буенча ведомствоара эш төркеме турындагы нигезләмәдә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау мәсьәләләре буенча ведомствоара эш төркеме (алга таба – Эш төркеме) республика башкарма хакимият органнарының, башка дәүләт органнарының, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның түбәндә аталган чараларны гамәлгә ашыру буенча эшен координацияләүне тәэмин итү өчен оештырылган ведомствоара органы булып тора:

Россия Федерациясе Президенты тарафыннан 2023 елның 30 декабрендә расланган Пр-2610 номерлы 2024–2028 елларда Россия Федерациясендә террорчылык идеологиясенә каршы көрәшү комплекслы планы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы карары белән расланган «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәшү» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау» буенча уртак юнәлешле чаралар комплексы.»;

4 пунктның җиденче абзацында «озак вакытка исәпләнгән республика һәм муниципаль комплекслы максатлы программалары» сүзләрен «Татарстан

Республикасы дәүләт программалары һәм муниципаль программалар» сүзләренә алмаштырырга;

7 пункттагы «квартал» сүзен «ярты ел» сүзенә алмаштырырга;

11 пунктның 4 абзацында «квартал саен» сүзләрен төшереп калдырырга;

Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау мәсьәләләре буенча ведомствоара эш төркеме составында эш төркеме әгъзасы С.А. Мостафинаның фамилиясен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Галиева-Мостафина».

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**